# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЫЗЫЛ БИСТӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

№ 15 от 23.04.2021г.

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Кызыл Бистә авыл җирлеге Башкарма комитетының «Капитал салуларны яклау һәм бүләкләү турында килешүләр төзү тәртибен һәм шартларын раслау хакында»гы 2021 елның 2 февралендәге 5 номерлы карары белән расланган капитал салуларны яклау һәм бүләкләү турында килешүләр төзү тәртибенә һәм шартларына үзгәрешләр кертү турында

"Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына территорияләрне комплекслы үстерүне тәэмин итү максатларында үзгәрешләр кертү турында" 2020 елның 30 декабрендәге 494-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Кызыл Бистә Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Кызыл Бистә Башкарма комитетының «Капитал салуларны яклау һәм бүләкләү турында килешүләр төзү тәртибен һәм шартларын раслау турында» гы 2021 елның 2 февралендәге 5 номерлы карары белән расланган капитал салуларны яклау һәм бүләкләү турында килешүләр төзү тәртибенә һәм шартларына үзгәрешләр кертү:

1.1. 6 пунктның 6.1.пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) административ-эшлекле үзәкләр һәм сәүдә үзәкләре (комплекслар), шулай ук күпфатирлы йортлар, торак йортлар (территорияне комплекслы үстерү турындагы шартнамә нигезендә мондый йортлар төзү очракларыннан тыш) төзү (модернизацияләү, реконструкцияләү).

2. Әлеге карарны Кызыл Бистә авыл җирлегенең мәгълүмати стендларда игълан итәргә һәм Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http://www.spasskiy.tatarstan.ru) һәм хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Кызыл Бистә авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе А.В. Алиев